КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 2 март г.Казань № б-340

Казан агломерациясенең нәтиҗәле һәм тотрыклы социаль-икътисадый һәм пространство үсешен тәэмин итү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан агломерациясенең комплекслы социаль-икътисадый һәм пространство үсеше схемасын раслау турында» 2025 ел, 12 апрель, 224 нче карары белән расланган Казан агломерациясенең социаль-икътисадый һәм пространство үсешенең комплекслы схемасын гамәлгә ашыру максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән Казан агломерациясенең социаль-икътисадый һәм пространство үсешенең комплекслы схемасын гамәлгә ашыру чаралары планын (алга таба – Чаралар планы) расларга.

2. Чаралар планының җаваплы башкаручылары булган республика башкарма хакимият органнарына аның үтәлешен, шулай ук, хисап елыннан соң килә торган елның 1 августыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын гамәлгә ашыруга мониторинг үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2024 ел, 13 гыйнвар, 3 нче карары нигезендә әзерләнә торган мониторинг нәтиҗәләре турында еллык докладта чагылдыру өчен «Татарстан Республикасының Пространство планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесенә ел саен мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

3. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Казан агломерациясе составына керүче Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына, шулай ук Чаралар планында күрсәтелгән оешмаларга Чаралар планын гамәлгә ашыруны, шулай ук, хисап елыннан соң килә торган елның 1 августыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын гамәлгә ашыруга мониторинг үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2024 ел, 13 гыйнвар, 3 нче карары нигезендә әзерләнә торган мониторинг нәтиҗәләре турында еллык докладта чагылдыру өчен «Татарстан Республикасының Пространство планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесенә ел саен мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 2 март, б-340 нчы
боерыгы белән расланды

Казан агломерациясенең социаль-икътисадый һәм пространство
үсешенең комплекслы схемасын гамәлгә ашыру
чаралары планы

| Т/с | Чара исеме | Үтәү срогы | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәһәр төзелеше һәм стратегик документация өлкәсендә | | |
| 1.1. | Казан агломерациясенең муниципаль берәмлекләрен территориаль планлаштыру схемаларын, шулай ук Казан агломерациясе муниципаль берәмлекләренең административ үзәкләренең генераль планнарын һәм җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан агломерациясен социаль-икътисадый һәм пространстволы үстерүнең комплекслы схемасын раслау турында» 2025 ел, 12 апрель, 224 нче карары белән расланган Казан агломерациясен социаль-икътисадый һәм пространстволы үстерүнең комплекслы схемасына (алга таба – Комплекслы схема) туры китерү | 2027 елның 31 декабренә кадәр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «Татарстан Республикасының Пространство планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең Казан агломерациясе составына керә торган җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) (килешү буенча) |
| 1.2. | Торак йортларны (күпфатирлы йортларны да һәм индивидуаль йортларны да) урнаштырырга рөхсәт ителә торган функциональ зона өчен билгеләнә торган торак фондының иң чик мәйданын билгеләгәндә Комплекслы | даими* | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | схеманың 1.1, 2.1 – 2.6 таблицаларында күрсәтелгән Казан агломерациясенең муниципаль берәмлекләре буенча мәгълүматларны куллану | | үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 1.3. | Планлаштыру карарлары составында һәм территорияләрне планлаштырып үстерү чиратында индивидуаль торак төзелеше объектларын урнаштыру карала торган территорияне планлаштыру документациясен раслаганда транспорт, инженерлык һәм социаль инфраструктуралар объектларын мондый объектларның минималь мөмкин булган тәэмин ителеш дәрәҗәсенең һәм максималь мөмкин булган территориаль файдалану дәрәҗәсенең норматив исәп-хисабы күрсәткечләре нигезендә урнаштыруны тәэмин итү | даими* | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 1.4. | Казан агломерациясенең транспорт (магистраль урам-юл челтәреннән файдалану мөмкинлеге булмаган), инженерлык һәм социаль инфраструктура белән тәэмин ителмәгән муниципаль берәмлекләре территориясендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләре проектларын әзерләү буенча методик таләпләр турында» 2024 елның 18 апрелендәге | даими* | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | 91/о номерлы боерыгы нигезендә җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләрен эшләгәндә территориянең фактта файдаланыла торган территориаль зонасын (Ф) билгеләүне тәэмин итү. Әлеге нигезләмәләр гражданнарның ташламалы категорияләренә, шул исәптән күпбалалы гаиләләргә бирү өчен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән килештерелгән җир кишәрлекләренә кагылмый | | |
| 1.5. | Гражданнарның ташламалы категорияләренә, шул исәптән күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү өчен билгеләнгән, транспорт (магистраль урам-юл челтәреннән файдалану мөмкинлеге булмаган), инженерлык һәм социаль инфраструктура белән тәэмин ителмәгән территорияләр өчен капиталь төзелеш объектларын төзергә рөхсәт ителә торган җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләрендә территориаль зоналарны алга таба билгеләү максатларында территорияне межалау проектларын (җир кишәрлекләре урнашу схемаларын) әзерләүне һәм килештерүне тәэмин итү | даими* | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 1.6. | Шәһәр төзелеше шартларына бәйле рәвештә, социаль объектлар, оештырылган рәвештә транспорт чараларын куеп тору өчен парковка | 2027 елның 31 декабренә кадәр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | урыннары, яшелләндерелгән гомуми файдаланудагы территорияләр һәм коммуналь билгеләнештәге башка объектлар белән тәэмин итүгә карата таләпләрне дифференциацияләү өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карарына үзгәрешләр кертү | | |
| 1.7. | Территорияләрне комплекслы үстерүне гамәлгә ашыру кысаларында территорияләрне үстерү һәм йортлар салу чараларын гамәлгә ашыру мөмкин булган территорияләргә карата тәкъдимнәр әзерләү | 2026 елның 31 декабренә кадәр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды (килешү буенча), «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 1.8. | «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү буенча барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең җир кишәрлекләре урнашу урыны һәм мәйданы өлешендә расланган территорияне межалау проектларына туры килмәве, шулай ук расланган территорияне межалау проектлары нигезендә дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләрен үзгәртеп кору мөмкин булмавы дәүләт кадастр исәбен һәм (яки) хокукларны дәүләт | 2026 елның 30 июненә кадәр | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | теркәвенә алуны гамәлгә ашыруны туктатып торуга нигез булып тору карала торган тәкъдимнәр әзерләү | | |
| 1.9. | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе эшен синхронлаштыруны тәэмин итү, шул исәптән Казан агломерациясенә карата расланган территорияне межалау проектлары турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү буенча дәүләт мәгълүмат системасыннан тапшыру өлешендә | даими* (әлеге Планның 1.8 пункты үтәлгәннән соң) | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 2. | Торак төзелеше өлкәсендә | | |
| 2.1. | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен Казан агломерациясе чикләрендә, беренче чиратта, әзер транспорт-инженерлык инфраструктурасы булган территорияләрдә (нәтиҗәле кулланылмый торган сәнәгать-склад мәйданчыкларын кертеп) күпфатирлы торак йортлар төзү өчен өстенлекле итеп билгеләү эшен оештыру | даими* | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 2.2. | Масштаблы инвестиция проектлары, шул исәптән «Олы Зеленодольск» проекты гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы Зеленодольск һәм Лаеш муниципаль районнары | даими* | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, Татарстан Республикасы Зеленодольск һәм Лаеш муни- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | территорияләрен Комплекслы схеманың 2.1 – 2.5 нче таблицаларында күрсәтелгән мәгълүматлар нигезендә билгеләнгән күләмнәрдә күпфатирлы торак йортлар төзү өчен рөхсәт ителә торган территорияләр итеп билгеләү эшен оештыру | | ципаль районнарының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 2.3. | Күпфатирлы торак төзелеше максатларында торак пунктлар чикләренә кертеп, җирләрне яки мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерүне гамәлгә ашыру тәкъдим ителми торган Питрәч, Биектау һәм Югары Ослан муниципаль районнары территорияләрен билгеләү эшен оештыру | даими* | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, Питрәч, Биектау, Югары Ослан районнарының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 2.4. | Казан агломерациясенең цифрлы (транспорт һәм баланс) модельләрен, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Цифрлы Татарстан» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2021 ел, 18 октябрь, 980 нче карары белән расланган «Цифрлы Татарстан» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «2025 – 2029 Татарстан Республикасы икътисад, социаль өлкә, дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә тармакларының алга киткән ИТ-чишелешләре» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында эшләүне дәвам итү | даими* | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | һәм алга таба аңа булышлык күрсәтеп тору | | |
| 3. | Транспорт инфраструктурасы өлкәсендә | | |
| 3.1. | Комплексលы схеманы әзерләү кысаларында эшләнгән Казан агломерациясенең транспорт математик моделенә исәпләнгән перспективалы йөкләнешне исәпкә алып, Комплекслы схеманың 4.1 рәсемендә каралган 2050 елга кадәр Казан агломерациясенең транспорт инфраструктурасын үстерү схемасы нигезендә төбәк һәм җирле әһәмияттәге яңа автомобиль юлларын, торак пунктларның урам-юл челтәре объектларын төзү һәм реконструкцияләү турында карарлар кабул итүне тәэмин итү | даими* | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 3.2. | Комплекслы схеманың 4.1 рәсемендә каралган 2050 елга кадәр Казан агломерациясенең транспорт инфраструктурасын үстерү схемасы нигезендә Казан агломерациясе территориясендә төбәк һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының һәм урам-юл челтәренең яңа участокларын төзү һәм булганнарын реконструкцияләү буенча уртача сроклы (өл ел) һәм озак сроклы (биш ел) планнар эшләү | 2026 елның 30 июненә кадәр | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ |
| 3.3. | Казан агломерациясе территориясендә әлеге Планның 3.2 пунктында күрсәтелгән төбәк һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының һәм урам-юл челтәренең яңа | 2026 елның 30 июненә кадәр | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | участокларын төзү һәм булганнарын реконструкцияләү планнарын дәүләт-хосусый партнерлык формасында гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр әзерләү | | |
| 3.4. | Үзәктән чыга торган магистральләрдә (Мамадыш трактын, Оренбург трактын, Себер трактын, Горький шоссесын кертеп) җәмәгать транспорты өчен бүленгән юллар буйлап тиз йөрешле автобус маршрутларын оештыру проектын эшләү | 2026 елның 31 декабренә кадәр | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 3.5. | Казан агломерациясе чикләрендә шәһәр яны маршрутларын Казан шәһәренең шәһәр муниципаль маршрутлары белән интеграцияләргә мөмкинлек бирәчәк җир өсте җәмәгать транспортының бердәм операторын билгеләү буенча тәкъдимнәр әзерләү | 2026 елның 30 июненә кадәр | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 3.6. | Үзәктән чыга торган магистральләрдә (Мамадыш трактын, Оренбург трактын, Себер трактын, Горький шоссесын кертеп) җәмәгать транспорты өчен бүленгән юллар буйлап тиз йөрешле автобус маршрутлары хәрәкәтен гамәлгә ашыру | 2026 елның 31 декабренә кадәр | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 3.7. | Пассажир агымы йөкләнеше нәтиҗәлелеге һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Казан агломерациясенең беренче поясы территориясенә хезмәт күрсәтү нәтиҗәлелеге буенча үсеш вариантларын бәяләп, Казан шәһәре метрополитенының һәм трамвай | 2026 елның 31 декабренә кадәр | «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «Татинвестгражданпроект» баш территориаль проект-тикшеренү фәнни-җитештерү фир- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | челтәренең перспектив үсеш схемасын эшләү | | масы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе (алга таба – «Татинвестгражданпроект» ДУП) |
| 3.8. | Әлеге Планның 3.7 пунктында каралган Казан шәһәре метрополитенын перспективалы үстерү схемасы нигезендә Казан шәһәре метрополитенының яңа станцияләрен һәм башка техник объектларын урнаштыруның техник коридорларына анализ ясау һәм планировка чишелешләрен әзерләү | 2026 елның 31 декабренә кадәр | «Татинвестгражданпроект» ДУП, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы |
| 3.9. | Казан шәһәре метрополитены линияләрен, станцияләрен һәм башка техник объектларын төзүнең техник мөмкинлеген мәҗбүри раслап, әлеге Планның 3.7 пунктында каралган Казан шәһәре метрополитенын перспективалы үстерү схемасын исәпкә алып, Казан шәһәре метрополитенының яңа станцияләренә якын территорияләрне үзләштерүне оештыру | даими* | Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 3.10. | Казан агломерациясе территориясендә йөк автотранспорты хәрәкәтен оптимальләштерү схемасын эшләү, Комплекслы схеманың 4.4.2 нче рәсемендә каралган 2050 елга кадәр Казан агломерациясенең логистика инфраструктурасын үстерү схемасы нигезендә беренче чираттагы чараларны билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру буенча «юл картасын» раслау | 2026 елның 30 июненә кадәр | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча), «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 3.11. | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Казан агломерациясе составына керә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территория-сендә транспорт-күчеп уты-ру үзәкләрен һәм күчеп утыру парковкаларын үстерү буенча тәкъдимнәр әзерләү, Комплекслы схеманың 4.3 нче рәсемендә каралган 2050 елга кадәр Казан агло-мерациясенең җәмәгать транспорты инфраструкту-расын үстерү схемасы нигезендә беренче чираттагы чараларны билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру буенча «юл картасын» раслау | 2026 елның 30 июненә кадәр | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Рес-публикасы Төзелеш, архитек-тура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 3.12. | Комплекслы схеманы һәм пассажирлар хәрәкәтенең интермодаль бурычларын исәпкә алып, Казан агло-мерациясе чикләрендә юл хәрәкәтен оештыруның ком-плекслы схемаларын һәм транспорт инфраструкту-расын комплекслы үстерү программасын, шул исәптән җир өсте җәмәгать транспор-тының өстенлекле хәрәкәтен билгеләү өлешендә актуаль-ләштерү | 2027 елның 31 декабренә кадәр | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча), «ТР Пространство планлаш-тыру институты» ДБУ |
| 3.13. | Россия Федерациясе Тран-спорт министрлыгының 2024 елның 28 декабрендәге ВИ-296-р номерлы боерыгы белән расланган «Яшәү өчен инфраструктура» илкүләм проектының «Җәмәгать транспортын үстерү» феде-раль проектындагы «Агло- | даими* | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | мерацияләрдә һәм шәһәрләрдә эксплуатация срогы норматив сроктан зуррак булмаган җәмәгать транспорты паркы өлеше» күрсәткечен исәпләп чыгару методикасы нигезендә Казан шәһәренең һәм Казан агломерациясе составына керә торган Татарстан Республикасы муниципаль районнарының транспорт предприятиеләрендәге җәмәгать транспортының күчмә составын ел саен яңартуны тәэмин итү | | |
| 3.14. | Җәмәгать транспорты маршрутларында брутто-контрактларга күчү буенча тәкъдимнәр әзерләү | 2026 елның 30 июненә кадәр | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы |
| 4. | Коммуналь инфраструктураны модернизацияләү өлкәсендә | | |
| 4.1. | Комплекслы схема нигезендә Казан агломерациясе территориясендә инженерлык инфраструктурасы участокларының кыйммәтен исәпләп чыгарып, су белән тәэмин итү, су чыгару (хуҗалык-көнкүреш һәм яңгыр канализациясе), газ белән тәэмин итү, җылылык белән тәэмин итү, электр белән тәэмин итү челтәрләренең яңа участокларын төзү һәм булганнарын реконструкцияләү буенча уртача сроклы (өч ел) һәм озак сроклы (биш ел) план эшләү | 2026 елның 30 июненә кадәр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 4.2. | Казан агломерациясе территориясендә гамәлдәге инженерлык челтәрләрен һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын | 2026 елның 30 июненә кадәр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | электрон төргә күчерү эшләрен башкару һәм Казан агломерациясе (Казан шәһәреннән тыш) территориясенә карата «Татарстан Республикасы инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының җыелма планы» мәгълүмат ресурсын булдыру | | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы |
| 5. | Социаль инфраструктураны үстерү өлкәсендә | | |
| 5.1. | Социаль инфраструктураның яңа объектларын урнаштыру буенча карарлар кабул ителгәндә Комплекслы схеманың 5.1 һәм 5.2 рәсемнәрендә каралган Казан агломерациясенең торак пунктларын рангларга бүлү өлешендә Комплекслы схема нигезләмәләрен куллануны тәэмин итү | даими* | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| 5.2. | Комплекслы схема нигезендә яңа социаль объектлар төзүнең уртача сроклы (өч ел) һәм озак сроклы (биш ел) планнарын эшләү | 2026 елның 31 декабренә кадәр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 6. | Инвестиция мохитен үстерү өлкәсендә | | |
| 6.1. | Комплекслы схеманың 3.1 нче рәсемендә каралган 2050 елга кадәр Казан агломерациясенең сәнәгать зоналарын урнаштыру зоналары схемасы нигезендә, Татарстан Республикасы Инвестиция картасына мәгълүматларны кертеп һәм Россия Федерациясенең инвестиция картасында | даими* | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | урнаштырып, яңа инвестиция мәйданчыклары булдыру өчен өстенлекле зоналар исемлеген формалаштыру | | |
| 6.2. | Үсеш планын булдырып, яңа инвестиция мәйданчыкларын билгеләү эшен синхронлаштыру һәм аларны юл һәм коммуналь инфраструктура белән тәэмин итү | даими* | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ |
| 6.3. | Инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда алга таба файдалану максатлары өчен җкишәрлекләрен әзерләүне тәэмин итү | даими* | Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 6.4. | Комплекслы схеманың 2.1 – 2.6 таблицаларында күрсәтелгән максатчан күрсәткечләр нигезендә территориаль планлаштыру схемаларын, генераль планнарны һәм территорияне планлаштыру документациясен эшләгәндә яңа предприятиеләр, производстволар урнаштыру һәм яңа эш урыннары булдыру буенча тәкъдимнәр әзерләү | даими* | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 6.5. | Икътисад тармаклары буенча инвестицияле тәкъдимнәр, шул исәптән проектларны дәүләт-шәхси партнерлык принципларында гамәлгә ашыру механизмнары кулланыла ала торган тәкъдимнәр әзерләү | 2026 елның 31 декабренә кадәр | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 6.6. | Икътисад таләпләре нигезендә гамәлдәге производстволар базасында яңа мәгариф һәм фәнни-җитештерү комплексларын үстерүне, шулай ук профильле белем бирү системасын үстерүне тәэмин итү («Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенең «Алабуга Политех» белем бирү үзәге тәҗрибәсен кулланып) | даими* | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «ТР Пространство планлаштыру институты» ДБУ |
| 7. | Демография һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә | | |
| 7.1. | Татарстан Республикасында туучылар санын арттыру буенча муниципаль программаларны (чаралар планнарын), шул исәптән Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы нигезендә актуальләштерү | 2026 елның 30 июненә кадәр | Җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы |
| 7.2. | Икътисадның өстенлекле тармаклары өчен кадрлар әзерләү, һөнәри яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрүнең нәтиҗәле системасын булдыру буенча өстәмә чаралар эшләү | даими* | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |
| 8. | Табигый рекреацион комплекс һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә | | |
| 8.1. | Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге аеруча саклана торган табигать территорияләре челтәрен саклауга һәм үстерүгә юнәл- | 2026 елның 31 декабренә кадәр | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
| --- | --- | --- | --- |
| | дерелгән чаралар планын әзерләү | | |
| 8.2. | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәлләре булган су объектлары өчен саклау зоналарын билгеләү чараларын үткәрү | 2030 елның 31 декабренә кадәр | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 8.3. | Яр буе линиясе (су объекты чикләре), су объектларының су саклау зоналары һәм яр буе саклау полосалары чикләре урнашу урынын билгеләү (дәүләт су реестрында өйрәнелү турында мәгълүматлар булганда), җирлектә су саклау зоналары һәм яр буе саклау полосалары чикләрен махсус мәгълүмат билгеләре белән ныгыту эшләрен үткәрү | 2030 елның 31 декабренә кадәр | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы |
| 8.4. | Урманнарны торгызу һәм урман утыртмаларын яшьләндерү чараларын үткәрүне тәэмин итү | даими* | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын гамәлгә ашыру мониторингын гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2024 ел, 13 гыйнвар, 3 нче карары нигезендә әзерләнә торган мониторинг нәтиҗәләре турында еллык докладта чагылдыру өчен «Татарстан Республикасының Пространство планлаштыру институты» ДБУнә ел саен мәгълүмат биреп.